**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Кодекса этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан

В целях совершенствования регулирования вопросов в области государственной гражданской службы Республики Татарстан, **постановляю:**

1. Утвердить Кодекс этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан (прилагается).

2. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить включение в служебные контракты государственных гражданских служащих Республики Татарстан, замещающих должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан, положений об ответственности за нарушение Кодекса этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

3. Предложить руководителям государственных органов Республики Татарстан, не являющихся исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, обеспечить включение в служебные контракты государственных гражданских служащих Республики Татарстан положений об ответственности за нарушение Кодекса этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

4. Рекомендовать лицам, замещающим государственные должности Республики Татарстан, соблюдать положения Кодекса этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан в части, не противоречащей правовому статусу этих лиц.

5. Рекомендовать органам местного самоуправления:

разработать и утвердить кодексы этики и служебного поведения муниципальных служащих;

включить в служебные контракты муниципальных служащих положения об ответственности за нарушение кодекса этики и служебного поведения муниципальных служащих.

6. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан.

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
23 марта 2011 года
№ УП-142

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан
от «23» марта 2011 года
№ УП-142

## Кодекс этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан

### I. Общие положения

1. Кодекс этики и служебного поведения государственных гражданских служащих Республики Татарстан (далее - Кодекс) разработан в соответствии с положениями Конституции Российской Федерации, Международного кодекса поведения государственных должностных лиц (Резолюция 51/59 Генеральной Ассамблеи ООН от 12 декабря 1996 года), Модельного кодекса поведения для государственных служащих (приложение к Рекомендации Комитета министров Совета Европы от 11 мая 2000 года № R (2000) 10 о кодексах поведения для государственных служащих), Модельного закона «Об основах муниципальной службы» (принят на 19-м пленарном заседании Межпарламентской Ассамблеи государств-участников Содружества Независимых Государств (постановление № 19-10 от 26 марта 2002 года), федеральных законов «О системе государственной службы Российской Федерации», «О государственной гражданской службе Российской Федерации», «О противодействии коррупции», других федеральных законов, содержащих ограничения, запреты и обязанности для государственных служащих Российской Федерации, Указа Президента Российской Федерации от 12 августа 2002 года № 885 «Об утверждении общих принципов служебного поведения государственных служащих» и иных нормативных правовых актов Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, Закона Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан, а также основан на общепризнанных нравственных принципах и нормах российского общества и государства.

2. Кодекс представляет собой свод общих правил профессиональной служебной этики и общих принципов и правил служебного поведения, которыми должны руководствоваться государственные гражданские служащие Республики Татарстан (далее – государственные служащие).

3. Гражданин Российской Федерации, поступающий на государственную гражданскую службу Республики Татарстан (далее –

государственная служба), обязан ознакомиться с положениями Кодекса и соблюдать их в процессе своей служебной деятельности.

4. Каждый государственный служащий должен принимать все необходимые меры для соблюдения положений Кодекса, а каждый гражданин Российской Федерации вправе ожидать от государственного служащего поведения в отношениях с ним в соответствии с положениями Кодекса.

5. Целью Кодекса является установление правил профессиональной служебной этики и правил служебного поведения государственных служащих для достойного выполнения ими своей профессиональной деятельности, а также содействие укреплению авторитета государственных служащих, доверия граждан к государственным органам Республики Татарстан и обеспечение единых норм поведения государственных служащих.

6. Кодекс призван повысить эффективность выполнения государственными служащими своих должностных обязанностей.

7. Кодекс служит основой для формирования должной морали в сфере государственной службы, уважительного отношения к государственной службе в общественном сознании.

8. Знание и соблюдение государственными служащими положений Кодекса является одним из критериев оценки качества их профессиональной деятельности и служебного поведения.

## II. Общие принципы и правила служебного поведения государственных служащих

9. Государственные служащие, сознавая ответственность перед государством, обществом и гражданами, призваны:

а) исполнять должностные обязанности добросовестно и на высоком профессиональном уровне в целях обеспечения эффективной работы государственных органов;

б) исходить из того, что признание, соблюдение и защита прав и свобод человека и гражданина определяют основной смысл и содержание деятельности государственных органов и государственных служащих;

в) осуществлять свою деятельность в пределах полномочий соответствующего государственного органа;

г) не оказывать предпочтения каким-либо профессиональным или социальным группам и организациям, быть независимыми от влияния отдельных граждан, профессиональных или социальных групп и организаций;

д) исключать действия, связанные с влиянием каких-либо личных, имущественных (финансовых) и иных интересов, препятствующих добросовестному исполнению ими должностных обязанностей;

е) соблюдать установленные федеральными законами ограничения и запреты, исполнять обязанности, связанные с прохождением государственной службы;

ж) соблюдать беспристрастность, исключающую возможность влияния на их служебную деятельность решений политических партий и общественных объединений;

з) соблюдать нормы служебной, профессиональной этики и правила делового поведения;

и) проявлять корректность и внимательность в обращении с гражданами и должностными лицами;

к) проявлять терпимость и уважение к обычаям и традициям народов России и других государств, учитывать культурные и иные особенности различных этнических, социальных групп и конфессий, способствовать межнациональному и межконфессиональному согласию;

л) воздерживаться от поведения, которое могло бы вызвать сомнение в добросовестном исполнении государственным служащим должностных обязанностей, а также избегать конфликтных ситуаций, способных нанести ущерб его репутации или авторитету государственного органа;

м) принимать предусмотренные законодательством Российской Федерации меры по недопущению возникновения конфликта интересов и урегулированию возникших случаев конфликта интересов;

н) не использовать служебное положение для оказания влияния на деятельность государственных органов, органов местного самоуправления, организаций, должностных лиц, государственных, муниципальных служащих и граждан при решении вопросов личного характера;

о) воздерживаться от публичных высказываний, суждений и оценок в отношении деятельности государственного органа или органа местного самоуправления, его руководителя, если это не входит в должностные обязанности государственного служащего;

п) соблюдать установленные в государственном органе правила публичных выступлений и предоставления служебной информации;

р) уважительно относиться к деятельности представителей средств массовой информации по информированию общества о работе государственного органа, а также оказывать содействие гражданам и организациям в получении достоверной информации в установленном порядке;

с) воздерживаться в публичных выступлениях, в том числе в средствах массовой информации, от обозначения стоимости в иностранной валюте (условных денежных единицах) на территории Российской Федерации товаров, работ, услуг и иных объектов гражданских прав, - сумм сделок между резидентами Российской Федерации, показателей бюджетов всех уровней бюджетной системы Российской Федерации, размеров государственных и муниципальных заимствований, государственного и муниципального долга, за исключением случаев, когда это необходимо для точной передачи сведений либо предусмотрено законодательством

Российской Федерации, международными договорами Российской Федерации, обычаями делового оборота;

т) постоянно стремиться к обеспечению как можно более эффективного распоряжения ресурсами, находящимися в сфере его ответственности.

10. Государственные служащие обязаны соблюдать Конституцию Российской Федерации, Конституцию Республики Татарстан, законы и иные нормативные правовые акты Российской Федерации и Республики Татарстан.

11. Государственные служащие в своей деятельности не должны допускать нарушение законов и иных нормативных правовых актов, исходя из политической, экономической целесообразности либо по иным мотивам.

12. Государственные служащие могут обрабатывать и передавать служебную информацию при соблюдении действующих в государственном органе норм и установленных требований.

13. Государственные служащие обязаны принимать соответствующие меры по обеспечению безопасности и конфиденциальности информации, за несанкционированное разглашение которой они несут ответственность и (или) которая стала известна им в связи с исполнением должностных обязанностей.

14. Государственные служащие, наделенные организационно-распорядительными полномочиями по отношению к другим государственным служащим, должны быть для них образцом профессионализма, безупречной репутации, способствовать формированию в государственном органе либо его подразделении благоприятного для эффективной работы морально-психологического климата.

15. Государственный служащий, наделенный организационно-распорядительными полномочиями по отношению к другим государственным служащим, несет ответственность в соответствии с законодательством Российской Федерации за действия или бездействие подчиненных ему сотрудников, нарушающих принципы этики и правила служебного поведения, если он не принял меры по недопущению таких действий или бездействия.

## III. Стандарт антикоррупционного поведения государственного служащего

16. Государственные служащие обязаны противодействовать проявлениям коррупции и предпринимать меры по ее профилактике в порядке, установленном нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

17. При назначении на должность государственной службы и исполнении должностных обязанностей государственный служащий обязан заявить о наличии или возможности наличия у него личной заинтересованности, которая влияет или может повлиять на надлежащее исполнение им должностных обязанностей.

18. Государственный служащий обязан представлять сведения о своих доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруга (супруги) и несовершеннолетних детей в соответствии с законодательством Российской Федерации.

19. Государственный служащий обязан уведомлять представителя нанимателя, органы прокуратуры Российской Федерации или другие государственные органы обо всех случаях обращения к нему каких-либо лиц в целях склонения его к совершению коррупционных правонарушений.

Уведомление о фактах обращения в целях склонения к совершению коррупционных правонарушений, за исключением случаев, когда по данным фактам проведена или проводится проверка, является должностной обязанностью государственного служащего.

20. Государственному служащему запрещается получать в связи с исполнением им должностных обязанностей вознаграждения от физических и юридических лиц (подарки, денежное вознаграждение, ссуды, услуги материального характера, плату за развлечения, отдых, за пользование транспортом и иные вознаграждения). Подарки, полученные государственным служащим в связи с протокольными мероприятиями, со служебными командировками и с другими официальными мероприятиями, признаются собственностью Республики Татарстан и передаются государственным служащим по акту в государственный орган, в котором он замещает должность государственной службы, за исключением случаев, установленных законодательством Российской Федерации.

21. Государственный служащий обязан:

а) предварительно уведомлять представителя нанимателя о намерении выполнять иную оплачиваемую работу;

б) получать письменное разрешение представителя нанимателя:

на занятие оплачиваемой деятельностью, финансируемой исключительно за счет средств иностранных государств, международных и иностранных организаций, иностранных граждан и лиц без гражданства, если иное не предусмотрено международным договором Российской Федерации или законодательством Российской Федерации;

на принятие наград, почетных и специальных званий (за исключением научных) иностранных государств, международных организаций, а также политических партий, других общественных объединений и религиозных объединений, если в должностные обязанности государственного служащего входит взаимодействие с указанными организациями и объединениями;

в) передавать принадлежащие государственному служащему ценные бумаги, акции (доли участия, паи в уставных (складочных) капиталах организаций) в доверительное управление в соответствии с законодательством Российской Федерации в случаях, если владение ими может привести к конфликту интересов;

г) использовать средства материально-технического и иного

обеспечения, другого государственного имущества только в связи с исполнением должностных обязанностей.

22. Государственные служащие, наделенные организационно-распорядительными полномочиями по отношению к другим государственным служащим, призваны:

а) принимать меры по предотвращению и урегулированию конфликта интересов своих подчиненных;

б) принимать меры по предупреждению коррупции среди подчиненных;

в) не допускать случаев принуждения государственных служащих к участию в деятельности политических партий и общественных объединений.

23. Государственные служащие, наделенные организационно-распорядительными полномочиями по отношению к другим государственным служащим, должны своим личным поведением подавать пример честности, беспристрастности и справедливости.

24. При наличии близкого родства или свойства (родители, супруги, дети, братья, сестры, а также братья, сестры, родители и дети супругов) между государственными служащими, замещающими должности государственной службы, связанные отношениями непосредственной подчиненности или подконтрольности, один из них обязан отказаться от замещения соответствующей должности государственной службы путем увольнения с государственной службы или перевода на другую должность государственной службы.

## IV. Общие правила профессиональной служебной этики государственных служащих

25. В служебном поведении государственному служащему необходимо исходить из конституционных положений о том, что человек, его права и свободы являются высшей ценностью и каждый гражданин имеет право на неприкосновенность частной жизни, личную и семейную тайну, защиту чести, достоинства, своего доброго имени.

26. В служебном поведении государственный служащий воздерживается от:

а) любого вида высказываний и действий дискриминационного характера по признакам пола, возраста, расы, национальности, языка, гражданства, социального, имущественного или семейного положения, политических или религиозных предпочтений;

б) грубости, проявлений пренебрежительного тона, заносчивости, предвзятых замечаний, предъявления неправомерных, незаслуженных обвинений;

в) угроз, оскорбительных выражений или реплик, действий, препятствующих нормальному общению или провоцирующих противоправное поведение;

г) курения во время служебных совещаний, бесед, иного служебного общения с гражданами.

27. Государственные служащие призваны способствовать своим служебным поведением установлению в коллективе деловых взаимоотношений и конструктивного сотрудничества друг с другом.

Государственные служащие должны быть вежливыми, доброжелательными, корректными, внимательными и проявлять терпимость в общении с гражданами и коллегами.

28. Государственному служащему при проведении проверки не следует вступать в такие отношения с руководством и сотрудниками проверяемой организации, которые могут его скомпрометировать или повлиять на его способность действовать независимо и объективно.

29. Государственный служащий не должен использовать свой официальный статус в интересах третьей стороны.

30. Внешний вид государственного служащего при исполнении им должностных обязанностей в зависимости от условий службы и формата служебного мероприятия должен способствовать уважительному отношению граждан к государственным органам, соответствовать общепринятому деловому стилю, который отличают официальность, сдержанность, традиционность, аккуратность.

## V. Конфликтные ситуации

31. Государственный служащий при выполнения своих должностных обязанностей не должен допускать возникновения конфликтных ситуаций.

Государственный служащий должен вести себя достойно, действовать в строгом соответствии с законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан, своим должностным регламентом, а также нормами настоящего Кодекса.

32. В случае, если государственному служащему не удалось избежать конфликтной ситуации, ему необходимо обсудить проблему конфликта с непосредственным руководителем.

Если непосредственный руководитель не может разрешить проблему или оказывается сам вовлечен в конфликтную ситуацию, государственному служащему следует уведомить об этом вышестоящего руководителя.

## VI. Ответственность за нарушение положений Кодекса

33. Нарушение государственным служащим положений настоящего Кодекса подлежит моральному осуждению на заседании соответствующей комиссии по соблюдению требований к служебному поведению государственных служащих и урегулированию конфликта интересов, образуемой в соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 25 августа 2010 года № УП-569 «О комиссиях по соблюдению требований к служебному поведению государственных гражданских служащих Республики Татарстан и урегулированию конфликта интересов», а в случаях, предусмотренных федеральными законами, нарушение положений Кодекса

влечет применение к государственному служащему мер юридической ответственности.

При проведении аттестации, формировании кадрового резерва на государственной гражданской службе Республики Татарстан, а также при наложении дисциплинарных взысканий учитывается соблюдение государственными служащими норм Кодекса.

---

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт контрактларына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын бозган өчен җаваплылык турындагы нигезләмәләрне кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары булмаган Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт контрактларына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын бозган өчен җаваплылык турындагы нигезләмәләрне кертүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексының әлеге затлар хокукый статусына каршы килмәгән өлешендәге нигезләмәләрен үтәүне тәкъдим итәргә.

5. Җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

муниципаль хезмәткәрләр этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын эшләргә һәм расларга;

муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт контрактларына муниципаль хезмәткәрләр этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексын бозган өчен җаваплылык турындагы нигезләмәләрне кертергә.

6. Әлеге Указны үтәүне контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 ел, 23 март
№ ПУ-142

Татарстан Республикасы
Президентының
2011 елның «23» мартындагы
ПУ-142 номерлы Указы белән
расланды

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексы

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексы (алга таба – Кодекс) Россия Федерациясе Конституциясе, Дәүләт вазыйфаи затлары тәртибенең халыкара кодексы (БМО Генераль ассамблеясының 1996 елның 12 декабрендәге 51/59 Резолюциясе), Дәүләт хезмәткәрләре тәртибенең модель кодексы (Европа Советы Министрлары комитетының дәүләт хезмәткәрләре өчен тәртип кодекслары турында 2000 елның 11 маендагы R (2000) 10 номерлы рекомендациясенә кушымта), «Муниципаль хезмәт нигезләре турында» Модель закон (Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Катнашучы дәүләтләр парламентара Ассамблеясының 19 нчы пленар утырышында кабул ителде (2002 елның 26 мартындагы 19-10 номерлы карар)), «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында», «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында», «Коррупциягә каршы тору турында» федераль законнар, Россия Федерациясе дәүләт хезмәткәрләре өчен чикләүләр, тыюлар һәм бурычлар каралган башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт хезмәткәрләре хезмәт тәртибенең гомуми принципларын раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 885 номерлы Указы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезләмәләренә таянып эшләнде, шулай ук Россия җәмгыятенең һәм дәүләтенең гомуми танылган әхлакый принципларына һәм нормаларына нигезләнде.

2. Кодекс Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) таянып эш итәргә тиешле һөнәри хезмәт этикасының гомуми кагыйдәләре һәм хезмәт тәртибенең гомуми принциплары һәм кагыйдәләре җыелмасыннан гыйбарәт.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – дәүләт хезмәте) керүче Россия Федерациясе гражданы Кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм үзенең хезмәт эшчәнлеге процессында аларны үтәргә бурычлы.

4. Һәр дәүләт хезмәткәре Кодекс нигезләмәләрен үтәү өчен кирәкле барлык чараларны күрергә тиеш, ә Россия Федерациясенең һәр гражданы үзе белән мөнәсәбәтләрдә дәүләт хезмәткәреннән Кодекс нигезләмәләренә туры килә торган тәртип көтәргә хокуклы.

5. Кодексның максаты булып дәүләт хезмәткәрләре үз һөнәри эшчәнлеген лаеклы башкарсын өчен аларның һөнәри хезмәт этикасы кагыйдәләрен һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук дәүләт хезмәткәрләренең абруен, гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт органнарына булган ышанычын ныгытуга булышлык һәм граждан хезмәткәрләре тәртибенең бердәй нормаларын тәэмин итү тора.

6. Кодекс дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан үз вазыйфаи бурычларын үтәүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән.

7. Кодекс дәүләт хезмәте өлкәсендә тиешле әхлак, иҗтимагый аңда дәүләт хезмәтенә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру өчен нигез булып хезмәт итә.

8. Дәүләт хезмәткәрләренең Кодекс нигезләмәләрен белүе һәм үтәве аларның һөнәри эшчәнлеге һәм хезмәт тәртибе сыйфатын бәяләү критерийларының берсе булып тора.

## II. Дәүләт хезмәткәрләре хезмәт тәртибенең гомуми принциплары һәм кагыйдәләре

9. Дәүләт хезмәткәрләре, дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдында җаваплылык тоеп, түбәндәгеләргә бурычлы:

а) дәүләт органнарының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү максатларында вазыйфаи бурычларын намус белән һәм югары һөнәри дәрәҗәдә үтәргә;

б) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау дәүләт органнары һәм дәүләт хезмәткәрләре эшчәнлегенең төп мәгънәсен һәм эчтәлеген билгеләвеннән чыгып эш итәргә;

в) үз эшчәнлеген тиешле дәүләт органы вәкаләтләре чикләрендә тормышка ашырырга;

г) нинди дә булса һөнәри һәм социаль төркемнәргә һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә, аерым гражданнар, һөнәри һәм социаль төркемнәр һәм оешмалар йогынтысына бирелмәскә;

д) вазыйфаи бурычларын намус белән үтәүгә киртә булган нинди дә булса шәхси, мөлкәти (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысы белән бәйле гамәлләр кылмаска;

е) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны сакларга, дәүләт хезмәте узу белән бәйле бурычларны үтәргә;

ж) аларның хезмәт эшчәнлегенә сәяси партияләр һәм җәмәгать оешмалары карарлары йогынты ясауны булдырмый торган гаделлекне сакларга;

з) хезмәт, һөнәри этика нормаларын, эштәге тәртип кагыйдәләрен сакларга;

и) гражданнар һәм вазыйфаи затлар белән мөгамәләдә нәзакәтле һәм игътибарлы булырга;

к) Россия һәм башка дәүләтләр халыклары йолаларына һәм гореф-гадәтләренә карата түземле һәм ихтирамлы булырга, төрле этник, социаль төркемнәрнең һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

л) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын намус белән үтәвенә шик уятуы мөмкин булган тәртиптән тыелырга, шулай ук аның исеменә һәм дәүләт органы абруена зыян китерердәй низаглы хәлләрне булдырмаска;

м) мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгуны булдырмау һәм килеп чыккан мәнфәгатьләр каршылыгы очракларын җайга салу буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрергә;

н) шәхси характердагы мәсьәләләрне хәл иткәндә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, дәүләт, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

о) әгәр бу дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычына кермәсә, дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы, аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата халык алдында сөйләүдән, фикер алышудан һәм бәя бирүдән тыелырга;

п) халык алдында чыгыш ясау һәм хезмәткә кагылышлы мәгълүмат бирүнең дәүләт органында билгеләнгән кагыйдәләрен үтәргә;

р) массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең җәмгыятькә дәүләт органы эше турында мәгълүмат бирү буенча эшчәнлегенә ихтирамлы мөнәсәбәттә булырга, шулай ук гражданнарның һәм оешмаларның дөрес мәгълүмат алуларына билгеләнгән тәртиптә ярдәм итәргә;

с) халык алдында чыгыш ясаганда, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, Россия Федерациясе территориясендә товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең һәм граждан хокукларының башка объектларының, – Россия Федерациясе резидентлары арасындагы эш йөртү суммаларын, Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләре бюджет күрсәткечләрен, дәүләт һәм муниципаль хисаплашулар, дәүләт һәм муниципаль бурычлар күләмен, төгәл мәгълүмат бирү кирәк булган яисә Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, эш башкару әйләнеше йолалары белән билгеләнү очракларыннан гайре, чит ил валютасында (шартлы акча берәмлегендә) бәясен билгеләүдән тыелырга;

т) даими төстә аның җаваплылыгы даирәсенә керә торган ресурслар белән мөмкин кадәр нәтиҗәле эш итүне тәэмин итүгә омтылырга;

10. Дәүләт хезмәткәрләре Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үтәргә бурычлы.

11. Дәүләт хезмәткәрләре үз эшчәнлекләрендә, сәяси, икътисадый максатка ярашлылыктан чыгып яисә башка сәбәпләр буенча, законнарның һәм башка норматив хокукый актларның бозылуына юл куймаска тиешләр;

12. Дәүләт хезмәткәрләре, дәүләт органында гамәлдә булган нормалар һәм билгеләнгән таләпләр үтәлгәндә, хезмәткә кагылышлы мәгълүматны эшкәртә һәм тапшыра алалар.

13. Дәүләт хезмәткәрләре санкциясез тараткан өчен үзләре җаваплы һәм (яки) аларга вазыйфаи бурычларын үтәгәндә билгеле булган мәгълүматның куркынычсызлыгын һәм конфеденциальлеген тәэмин итү өчен тиешле чаралар күрергә бурычлы.

14. Башка дәүләт хезмәткәрләренә карата оештыру-күрсәтмә бирү вәкаләтләре бирелгән дәүләт хезмәткәрләре алар өчен һөнәри осталык, намуслылык өлгесе булырга, дәүләт органында яисә аның бүлекчәсендә нәтиҗәле эш өчен уңайлы әхлакый-психологик климат формалаштырырга булышырга тиешләр.

15. Башка дәүләт хезмәткәрләренә карата оештыру-күрсәтмә бирү вәкаләтләре бирелгән дәүләт хезмәткәрләре үз кул астында эшләүче, этика принципларын һәм хезмәт тәртибен бозучы хезмәткәрләрнең гамәлләре яисә гамәл кылмаулары өчен, әгәр ул мондый гамәлләрне һәм гамәл кылмауны булдырмау өчен чаралар күрмәгән булса, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## III. Дәүләт хезмәткәренең коррупциягә каршы торуы стандарты

16. Дәүләт хезмәткәрләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә коррупция очракларына каршы көрәшергә һәм аны кисәтү буенча чаралар күрергә бурычлы.

17. Дәүләт хезмәтенә билгеләнгән һәм хезмәт бурычларын башкарган вакытта дәүләт хезмәткәре үзенең вазыйфаи бурычларын үтәвенә йогынты ясый торган яисә йогынты ясавы мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләре булуы яки булу мөмкинлеге турында әйтергә бурычлы.

18. Дәүләт хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар бирергә бурычлы.

19. Дәүләт хезмәткәре эшкә яллаучы вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына яки башка дәүләт органнарына аңа нинди дә булса затларның аны коррупциягә бәйле хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итүенең барлык очраклары турында хәбәр итәргә бурычлы.

Коррупциягә бәйле хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, әлеге фактлар буенча тикшерү уздырылган булу яисә уздырылу очракларыннан гайре, хәбәр итү дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычы булып тора.

20. Дәүләт хезмәткәренә үз вазыйфаи бурычларын үтәгән өчен физик һәм юридик затлардан түләүләр (бүләкләр, акчалата түләү, ссудалар, матди характердагы хезмәт күрсәтүләр, күңел ачкан, ял иткән, транспорттан файдаланган өчен түләү һәм башка түләүләр) кабул итү тыела. Протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә дәүләт хезмәткәре алган бүләкләр Татарстан Республикасы милке дип таныла һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, үзе дәүләт хезмәте вазыйфасы биләгән дәүләт органына акт буенча тапшырыла.

21. Дәүләт хезмәткәре түбәндәгеләргә бурычлы:

а) эшкә яллаучы вәкиленә башка түләүле эш башкару нияте барлыгы турында алдан ук хәбәр итәргә;

б) эшкә яллаучы вәкиленең язма рөхсәтен алырга:

әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, фәкать чит ил дәүләте, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән финанслана торган түләүле эш белән шөгыльләнүгә;

әгәр әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычына керсә, чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка җәмәгать берләшмәләре һәм дини берләшмәләр бүләкләрен, мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен (гыйльми дәрәҗәләрдән тыш) алуга;

в) дәүләт хезмәткәре ия булган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталындагы катнашу өлешләрен, пайларны), аларга ия булу мәнфәгатьләр каршылыгына китерү мөмкин булганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга;

г) матди-техник һәм бүтән тәэмин итү чараларын, башка дәүләт мөлкәтен бары тик вазыйфаи бурычларын үтәгәндә генә файдаланырга.

22. Башка дәүләт хезмәткәрләренә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән дәүләт хезмәткәрләре:

а) үз кул астында эшләүчеләрнең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрергә;

б) үз кул астында эшләүчеләр арасында коррупцияне кисәтү буенча чаралар күрергә;

в) дәүләт хезмәткәрләрен сәяси партияләр һәм җәмәгать оешмалары эшчәнлегендә катнашырга мәҗбүр итү очракларына юл куймаска тиеш.

23. Башка дәүләт хезмәткәрләренә карата оештыру-күрсәтмә бирү вәкаләтләре бирелгән дәүләт хезмәткәрләре үзләренең шәхси тәртибе белән намуслылык, гаделлек һәм турылык үрнәге булырга тиешләр.

24. Турыдан-туры кул астында эшләү яисә контрольдә булу мөнәсәбәтләре белән бәйле дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләре арасында якын кардәшлек (ата-ана, ир белән хатын, балалар, абыйлы-сеңелле, апалы-энеле, иренең яисә хатынының ата-анасы яисә

балалары) булганда, аларның берсе, дәүләт хезмәтеннән китеп яки дәүләт хезмәтенең башка вазыйфасына күчеп, дәүләт хезмәтенең әлеге вазыйфасын биләүдән баш тартырга тиеш.

## IV. Дәүләт хезмәткәрләре һөнәри хезмәт этикасының гомуми кагыйдәләре

25. Дәүләт хезмәткәренә үзенең хезмәт тәртибендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң югары кыйммәтләр булып торуы һәм һәр гражданның шәхси тормышы кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, намусын, абруен, яхшы исемен саклауга хокуклы булуы турындагы конституциячел нигезләмәләрдән чыгып эш итәргә кирәк.

26. Дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибендә түбәндәгеләрдән тыела:

а) кешенең җенесе, яше, расасы, милләте, теле, гражданлыгы, социаль, мөлкәти яки гаилә хәле, сәяси һәм дини өстенлекләре билгеләренә карап дискриминацион характердагы теләсә нинди фикер белдерүдән һәм гамәл кылудан;

б) тупаслыктан, мыскыллы тон, өстенлек күрсәтүдән, алдан ук ялгыш кисәтүләрдән, хаксыз, нахак гаепләүләр ташлаудан;

в) нормаль аралашуга киртә яки хокукка каршы гамәлләргә этәрүе мөмкин булган янаулардан, мәсхәрәле гыйбарәләрдән һәм сүзләрдән, гамәлләрдән;

г) хезмәт киңәшмәләре, әңгәмәләр, гражданнар белән хезмәт буенча башкача аралашу вакытында тәмәке тартудан.

27. Дәүләт хезмәткәрләре үзләренең хезмәт тәртибе белән коллективта эшлекле мөнәсәбәтләр һәм бер-берсе белән конструктив хезмәттәшлек урнашуга ярдәм итәргә тиешләр.

Дәүләт хезмәткәрләре әдәпле, хәерхаһлы, нәзакәтле, игътибарлы булырга һәм гражданнар һәм хезмәттәшләре белән мөгамәләдә түземлек күрсәтергә тиешләр.

28. Тикшерү уздырганда дәүләт хезмәткәренә тикшерелә торган оешманың җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре белән үзенә карата компромат буларак кулланылырлык яки аның бәйсез һәм объектив эш итү мөмкинлегенә йогынты ясарлык мөнәсәбәтләргә керергә ярамый.

29. Дәүләт хезмәткәре үзенең рәсми статусын өченче як мәнфәгатьләрендә файдаланырга тиеш түгел.

30. Хезмәт вазыйфаларын башкарганда, хезмәт шартларына һәм хезмәт чарасы форматына бәйле рәвештә, дәүләт хезмәткәренең тышкы кыяфәте гражданнарның дәүләт органнарына ихтирамлы мөнәсәбәтенә этәргеч бирергә, рәсмилек, тыйнаклык, традицияләр, пөхтәлек белән аерылып торучы гомум кабул ителгән эш стиленә туры килергә тиеш.

## V. Конфликтлы вәзгыять

31. Дәүләт хезмәткәре үзенең хезмәт вазыйфаларын башкарганда конфликтлы вәзгыять килеп чыгуга юл куймаска тиеш.

Дәүләт хезмәткәре үзен лаеклы тотарга, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, үзенең вазыйфаи регламентына, шулай ук әлеге Кодекс нормаларына катгый нигезләнеп эш итәргә тиеш.

32. Дәүләт хезмәткәре конфликтлы вәзгыятьне булдырмый кала алмаганда, ул конфликт мәсьәләсен турыдан-туры җитәкчесе белән тикшерергә тиеш.

Әгәр турыдан-туры җитәкче мәсьәләне хәл итә алмый яки үзе үк конфликтлы вәзгыятьтә катнаша икән, дәүләт хезмәткәре бу турыда югарырак җитәкчегә хәбәр итәргә тиеш.

## VI. Кодекс нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык

33. Дәүләт хезмәткәренең әлеге Кодекс нигезләмәләрен бозуы Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәве һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә оештырылган дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәве һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында әхлакый яктан гаепләнергә тиеш, ә федераль законнарда каралган очракларда, Кодекс нигезләмәләрен бозу дәүләт хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чаралары кулланылуга китерә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә аттестация уздырылганда, кадрлар резервы формалаштырылганда, шулай ук дисциплинар җәза бирелгәндә дәүләт хезмәткәрләренең Кодекс нормаларын үтәве исәпкә алына.

---